СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

6.12.2019 № 37/8

На № __________ от _______________

**«2018-2020 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү» район программасы үтәлеше турында**

«2018-2020 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү район программасы үтәлеше турында» мәгълүматны тыңлап фикер алышканнан соң, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Мәгълүматны исәпкә алырга.

2. Район Башкарма комитетынатүбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

- 2018-2020 елларга Тукай муниципаль районы халкы арасында сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру, алкоголь продукциясен, сыра һәм тәмәке куллануны киметү буенча муниципаль программа чараларын гамәлгә ашыруны;

- спортның абруен күтәрүгә һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга юнәлтелгән муниципаль чаралар һәм акцияләр үткәрүне.

3. Авыл җирлекләре Башлыкларына тәкъдим итәргә:

- 2020 елга авыл җирлеге территориясендә уздырырга планлаштырылган чаралар планына тәкъдимнәр кертергә;

- авыл җирлеге территориясендә урнашкан җәмәгать оешмаларын, хезмәт коллективларын сәламәт яшәү рәвешен тәрбияләүдә катнашуга җәлеп итәргә.

4. «Якты юл» («Светлый путь») газетасы редакциясенә район халкының сәламәт яшәү рәвешен формалаштыруга, районда туып-үскән танылган спортчыларның тормышы һәм эшчәнлеге турында материаллар бастырып чыгару эшен оештырырга.

5. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны социаль мәсьәләләр, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Ф.М. Камаев